| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДЕВЯТЕРНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕВӘТЕРНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.04.2020 Девәтернә авылы № 11

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

«Татарстан Республикасы территориясендә аерым янгынга каршы режим билгеләү турында» 2020 елның 01 апрелендәге 242 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү максатында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, ачык территорияләрдә ландшафт янгыннары артуга бәйле рәвештә, Девәтернә авыл җирлеге территориясендә язгы-җәйге чорда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Билгеләргә:

- 2020 елның 10 апреленнән 17 майга кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертелә дип.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим чараларының кушымтада бирелгән планын расларга.

3. 2020 елның 10 апреленнән 17 маена кадәр чорда тыярга:

- коры үлән һәм чүп-чар яндыруны;

- Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрендә хәвефнең 1-3 класслы пиротехник эшләнмәләр куллануны, урман янгыннарына, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләренә, балалар ялы оешмаларына һәм аларны савыктыру оешмаларына, урман кишәрлекләре белән чиктәш экономика объектларына, савыктыру оешмаларына, шулай ук урман-парк